| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН<br>ГЛАВА АМЗИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ӘМЗӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Яңа Әмзә ав. **КАРАР**

«02» ноябрь 2023 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Яңа Әмзә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2023 елның 24 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Яңа Әмзә авылы, Ленин урамы, 12нче йорт адресы буенча урнашкан Яңа Әмзә авылы мәдәният йорты бинасы янында Нурлат муниципаль районы Әмзә авылы Ленин, Совет, Гагарин, Вахитов, Полевая, Садовая, М. Җәлил, Тукай, Мәктәп, Кооператив, Татарстан, Пионер, Горький урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Авыл җирлеге башлыгы һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Яңа Әмзә авылында яшәүче, 1 гр инвалидтан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Яңа Амзя авылындагы чишмә территориясен төзекләндерү;

Яңа Амзя авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге поселок эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

- Яңа Әмзә авылы чикләрендә авыл эчендәге юлларны карап тоту;

- җәяүлеләр күперен ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында

http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Әмзә авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әмзә авыл җирлеге башлыгы Ә..Ф.Сафиуллина